**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

30.06.2022 № 216

**2022–2023 еллар чорына алар тарафыннан электр энергиясен куллану режимын чикләү икътисадый, экологик, социаль нәтиҗәләргә китерүе мөмкин булган электр энергиясен (куәтен) кулланучылар исемлеген раслау турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 4 маендагы 442 номерлы боерыгы белән расланган электр энергиясен куллану режимын тулысынча һәм (яисә) өлешчә чикләү кагыйдәләренең 15, $15^{1}$ пунктлары нигезендә:

1. 2022–2023 еллар чорына алар тарафыннан электр энергиясен куллану режимын чикләү икътисадый, экологик, социаль нәтиҗәләргә китерүе мөмкин булган электр энергиясен (куәтен) кулланучыларның кушымтада бирелгән исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «2021–2022 еллар чорына алар тарафыннан электр энергиясен куллану режимын чикләү икътисадый, экологик, социаль нәтиҗәләргә китерүе мөмкин булган электр энергиясен (куәтен) кулланучылар исемлеген раслау турында» 2021 елның 30 июнендәге 196 номерлы боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**